**КАРАР**

**31 август 2024 ел** **№ 3**

**Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Туембаш авылында «Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Туембаш авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 27 ноябрендәге 1 номерлы Туембаш авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 31 августында түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Туембаш авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 27 ноябрендәге 1 номерлы Туембаш авылы гражданнар җыены карарына 2024 елның 20 мартындагы 2 номерлы карары редакциясендә түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- 2 пунктта:

а) унөченче абзацта ясалма тигезсезлекне, җәяүлеләр өчен кичүне көйләү, урнаштыру һәм карап тоту, Туембаш авылының, Ленин урамы буенча җәяүлеләр өчен кичүен яктырту, проект-смета документациясе, сатып алу, җайланма сүзләрен өстәргә;

б) унтугызынчы абзацны төшереп калдырырга»?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 396 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 201.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 201 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлеге Туембаш авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Туембаш авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 27 ноябрендәге 1 номерлы Туембаш авылы гражданнар җыены карарына 2024 елның 20 мартындагы 2 номерлы карары редакциясендә түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- 2 пунктта:

а) унөченче абзацта ясалма тигезсезлекне, җәяүлеләр өчен кичүне көйләү, урнаштыру һәм карап тоту, Туембаш авылының, Ленин урамы буенча җәяүлеләр өчен кичүен яктырту, проект-смета документациясе, сатып алу, җайланма сүзләрен өстәргә;

б) унтугызынчы абзацны төшереп калдырырга»?

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Туембаш авыл җирлеге башлыгы: И.Ф. Гарипов